МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.04.2024 Казан ш. №под-779/24

Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезендә боерык бирәм:

1. Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

«Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 27.05.2021 №под-777/21;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү буенча дәүләт хезмәте

күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 27.05.2021 №под-777/21 боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 15.11.2021 №под-1459/21.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү һәм укучыларның йомгаклау аттестациясе бүлегенә (Л.И.Сәүбанова) боерык чыккан көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары М.З.Закировка йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән
министрлыгының 09.04.2024
№под-779/24 боерыгы белән
расланды

**Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Административ регламент) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

Дәүләт хезмәте түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына беренче сыйныфка укырга керү турында гаризалар кабул итү,

башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яки) урта гомуми белем алмаган һәм тиешле дәрәҗәдәге белем алу хокукына ия булган затларны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яки) урта гомуми белем алу өчен укырга кабул итү турында Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына гаризалар кабул итү;

Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына башка белем бирү оешмасыннан күчерү тәртибендә укырга кабул итү турында гаризалар кабул итү,

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – Белем турында закон) 67 статьясындагы 5 өлешендә каралган очракларда аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнеп, төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен яисә профильле укыту өчен Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү яисә дәүләт белем бирү оешмаларына күчерү турында гаризалар кабул итү.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – аларны гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы башкара торган Татарстан Республикасынфң гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт белем бирү оешмаларына (алга таба – Оешма) мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар.

Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышаныч кәгазе нигезендә гамәл кылучы затлар эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте алу хокукына ия булган мөрәҗәгать итүчеләр категорияләре:

1.3.1. Балалары «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 44 статьясындагы 5 пункты, «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 19 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясе Тикшерү комитеты турында» 2010 елның 28 декабрендәге 403-ФЗ номерлы федераль законның 35 статьясындагы 25 өлеше нигезендә интернатка ия булган Оешмада дәүләт хезмәтеннән файдалануга чираттан тыш хокуклы булган ата-аналар (законлы вәкилләр).

1.3.2. Балалары «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясындагы 8 пункты нигезендә Оешмада дәүләт хезмәте алуга чираттан тыш хокуклы булган ата-аналар (законлы вәкилләр) һәм аларның гаиләләренең яшәү урыны буенча «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» 2016 елның 3 июлендәге 226-ФЗ номерлы федераль законның $28^1$ статьясында күрсәтелгән балалар.

1.3.3. «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы федераль законның 19 статьясындагы 6 өлешенең икенче абзацында, «Полиция турында» 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 6 өлешендә каралган Оешмада дәүләт хезмәте алуга беренче чиратта хокуклы булган, яшәү урыны яки тору урыны буенча Оешмага беркетелгән территориядә теркәлгән балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре);

1.3.4. Эчке эшләр органнарының полиция хезмәткәрләре булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре), «Кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 30 декабрендәге 283-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясындагы 14 өлешендә күрсәтелгән балаларның ата-аналары.

1.3.5. Балаларының Мәгариф турында законның 67 статьясындагы $3^1$ өлешендә, 86 статьясындагы 6 өлешендә каралган Оешмада дәүләт хезмәтен алуга өстенлекле хокукы булган ата-аналар (законлы вәкилләр).

1.3.6. Татарстан Республикасы территориясендә яшәү яисә тору урыны буенча теркәү исәбен алу органнары тарафыннан теркәлгән һәм Оешмага беркетелгән территориядә яшәүче балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре).

1.3.7. Балалары Оешмага беркетелгән территориядә яшәми торган ата-аналар (законлы вәкилләр).

1.3.8. 14 яшькә җиткән балигъ булмаган (укырга керүче), законлы вәкилләр ризалыгы белән гамәл итүче затлар

1.3.9. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яки) урта гомуми белем алмаган һәм тиешле дәрәҗәдәге белем алу хокукына ия булган (укырга керүче), Татарстан Республикасы территориясендә яшәү яки тору урыны буенча теркәлгән һәм Оешмага беркетелгән территориядә яшәүче балигъ булган затлар.

1.3.10. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яисә) урта гомуми белем алмаган һәм тиешле дәрәҗәдәге белем алу хокукына ия булган (укырга керүче), Татарстан Республикасы территориясендә яшәү яки тору урыны буенча теркәлгән һәм Оешмага беркетелгән территориядә яшәмәгән балигъ булган затлар.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета

нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү (алга таба – укырга кабул итү турында гариза кабул итү).

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы орган – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Дәүләт хезмәте турыдан-туры Оешмалар тарафыннан кушымтадагы исемлеккә (1 нче кушымта (белешмәлек) ярашлы рәвештә күрсәтелә.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмасына кабул итү турында гариза кабул итү турында белдерү;

гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмасына кабул итү турында гаризаны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

2.3.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен бирүгә нигез булган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында карарны үз эченә алган документның атамасы һәм реквизитлары составы.

укырга кабул итү турында гаризаны кабул итү яисә кабул итүдән баш тарту турында белдерү (алга таба – гариза, укырга кабул итү турында гариза) әлеге Административ регламентның 4 нче һәм 5 нче кушымталарында билгеләнгән рәвешләрдә формалаштырыла.

2.3.2.1. Гариза кабул итү турында белдерү реквизитлары (әлеге Административ регламентка 4 нче кушымта):

датасы, номеры;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

баланың яки укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

гариза кабул итүче Оешманың исеме;

гаризаны теркәү көне һәм номеры;

кабул ителгән документлар турында мәгълүмат, шул исәптән Оешмага бару өчен тәкъдим ителгән дата һәм вакыт күрсәтелгән чираттан тыш, беренче чиратта яки өстенлекле кабул итү хокукы турында мәгълүмат (соңгысы – шундый хокук булганда);

Оешманың телефоны;

Оешманың вәкаләтле затының вазыйфасы;

Оешманың вәкаләтле затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында мәгълүмат (соңгысы – булган очракта).

2.3.2.2. Гаризаны кабул итүдән баш тарту турында белдерү реквизитлары (әлеге Административ регламентка 5 нче кушымта):

датасы, номеры;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

гариза кабул итүче Оешманың исеме;

гаризаны теркәү көне һәм номеры;

әлеге Административ регламент нигезендә баш тарту нигезенең исеме;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен аңлату;

Оешманың телефоны;

Оешманың вәкаләтле затының вазыйфасы;

Оешманың вәкаләтле затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында мәгълүмат (соңгысы – булган очракта).

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.4. Бирелгән гариза нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Бердәм порталга интеграллаштырылган «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы» төбәк мәгълүмат системасында (алга таба – Төбәк порталы) (https://uslugi.tatarstan.ru/), «Татарстан Республикасы электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә сайланган ысул нигезендә түбәндәгеләр (бирелә) җибәрелә:

мөрәҗәгать итүчегә шәхсән кәгазь чыганакта яисә, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән;

электрон почта адресы буенча электрон документ формасында һәм (яки) Бердәм порталда, Төбәк порталында гариза бирүченең шәхси кабинетына.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында документ биреп беренче сыйныфка кабул итү турында гаризаны кабул иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты:

әлеге Административ регламентның 1.3.1-1.3.6, 1.3.9 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен, Оешмада укуга чираттан тыш, беренче

чиратта, өстенлекле хокукы булган балаларга һәм беркетелгән территориядә яшәүче балаларга беренче сыйныфка кабул итү турында гаризаны кабул иткән көннән алып (агымдагы елның 1 апреленнән 30 июненә кадәр) биш эш көне дәвамында;

әлеге Административ регламентның 1.3 пунктындагы 1.3.7, 1.3.10 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен, Оешмага беркетелгән территориядә яшәмәгән балалар өчен беренче сыйныфка кабул итү турында гаризалар теркәлгән көннән алып – биш эш көне дәвамында, 1 сыйныфка кабул итү турында гариза кабул иткәндә – агымдагы елның 6 июленнән башлап буш урыннар тутырылганчыга кадәр, әмма агымдагы елның 5 сентябреннән дә соңга калмыйча.

Укучыларны бер Оешмадан икенчесенә күчерү очрагында кабул итү турында гаризаны кабул иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты әлеге Административ регламентның 2.6.1.2 пунктындагы 2.6.1.2 пунктчасында күрсәтелгән документларны кабул итү турында гаризаны теркәгән көннән алып өч эш көне тәшкил итә.

Аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнүле төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен яки индивидуаль сайлап алу нәтиҗәләре буенча профильле уку өчен укучыларны кабул итү яки дәүләт белем бирү оешмаларына күчерү турында гариза кабул иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты Оешма тарафыннан кабул итү турында гариза теркәлгәннән соң өч эш көне тәшкил итә. Индивидуаль сайлап алу Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнеп яки профильле укыту өчен төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибен раслау турында» 27.02.2015 ел, №1156/15 боерыгы белән билгеләнгән тәртип буенча башкарыла.

2.4.2. Киләсе уку елына түбәндәге категорияләр буенча беренче сыйныфларга кабул итү турында гаризалар бирү чоры:

2.4.2.1. балалары Оешмага беркетелгән территориядә яшәүче һәм балалары чираттан тыш, беренче чиратта, өстенлекле нигездә кабул итү хокукына ия булган гариза бирүчеләр өчен – беренче сыйныфка кабул итү турында гариза кабул иткәндә 1 апрельдән дә соңга калмыйча һәм агымдагы елның 30 июнендә тәмамлана;

Гариза агымдагы елның 30 июненнән соң бирелгән очракта, кабул итү гомуми нигездә башкарыла.

Беркетелгән территориядә яшәүче барлык балаларны беренче сыйныфка кабул итүне тәмамлаган белем бирү оешмалары 6 июльдән иртәрәк чорда беркетелгән территориядә яшәмәгән балаларны кабул итә.

2.4.2.2 балалары Оешмага беркетелгән территориядә яшәмәгән гариза бирүчеләр өчен – агымдагы елның 6 июленнән буш урыннар тулганчыга кадәр, әмма агымдагы елның 5 сентябреннән дә соңга калмыйча – беренче сыйныфка кабул итү турында гариза кабул иткәндә.

2.4.2.3. Агымдагы уку елына беренче-унберенче сыйныфларга кабул итү турында гаризалар бер Оешмадан икенчесенә күчерү тәртибендә буш урыннар булганда уку елы дәвамында кабул ителә.

2.4.2.4. Аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнеп төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен яисә индивидуаль сайлап алу нәтиҗәләре буенча профильле уку өчен дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү яисә күчерү турында гаризалар

кабул итү Мәгариф турында законның 67 статьясының 5 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 27.02.2015 ел, №1156/15 боерыгы белән расланган Аерым укыту предметларын тирәнтен өйрәнеп төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен яисә профильле укыту өчен Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына кабул иткәндә яисә күчергәндә укучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Кабул итү турында гариза һәм кушымта итеп бирелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән срокларда түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

Оешмага шәхсән барган очракта – кәгазь чыганакларда;

гомуми файдаланудагы почта элемтәсе операторлары аша, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы хат белән;

63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә ярашлы рәвештә имзаланган (расланган) электрон формада Бердәм портал, Төбәк порталы аша.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

2.5.1. Бердәм порталда, Төбәк порталында, Министрлык сайтында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгатьнең категориясенә һәм нигезенә карамастан түбәндәге документларны тәкъдим итә:

Бердәм портал, Төбәк порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә ярашлы рәвештә имзаланган документ формасындагы гариза (әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта, үрнәк формасы (гариза формасы Оешма тарафыннан билгеләнә) яки электрон формада (интерактив формага тиешле мәгълүмат кертү юлы белән тутырыла);

мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документ (Оешмага шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта күрсәтелә). Бердәм портал, Төбәк порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документ белешмәләре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – Бердәм система)» федераль дәүләт

мәгълүмат системасында исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Чит ил гражданины яки гражданлыгы булмаган зат булган мөрәҗәгать итүче «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясына ярашлы рәвештә чит ил гражданины яки гражданлыгы булмаган затның шәхесен раслаучы документны тапшыра.

2.6.1.1. Кабул итү турында гаризаны кабул итү өчен баланың ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкиле (вәкилләре)) яки укырга керүче бала гариза белән бергә түбәндәге документларны тапшыра:

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсе, аның рус теленә нотариаль расланган тәрҗемәсе;

Чит ил гражданины яки гражданлыгы булмаган баланың ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкиле (вәкилләре)) өстәмә рәвештә гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) туганлыгын (яки бала хокукларында эш итүнең законлылыгын) раслаучы документны һәм баланың Россия Федерациясендә булу хокукын раслаучы документны тапшыра;

бер ата-анадан һәм бер ата-анадан тумаган ир туганының һәм (яки) кыз туганының (бер ата-анадан һәм бер ата-анадан тумаган ир туганы һәм (яки) кыз туганы укый торган дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасына баланы гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча өстенлекле рәвештә кабул итү хокукын кулланган очракта) туу турында чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе, аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;

баланың яшәү урыны буенча теркәлүен рәсмиләштерү өчен документлар кабул итү турындагы белешмәнең күчермәсе (баланы теркәү турында документ булмаган очракта яки яшәү урыны буенча яки беркетелгән территориядә булган урында һәм баланы яки беркетелгән территориядә яшәүче баланы укырга кабул иткән очракта);

гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе;

әгәр күрсәтелгән документ белән расланган белем Россия Федерациясендә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, №273-ФЗ федераль законның 107 статьясы нигезендә тиешле белем дәрәҗәсендә танылa икән, чит дәүләт территориясендә бирелгән белем турында документ күчермәсе һәм аның чит телгә нотариаль расланган тәрҗемәсе (урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча кабул ителгәндә яки укырга күчерелгәндә);

дәүләт хезмәте күрсәтү буенча мөрәҗәгать итүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең мәнфәгатьләрен таныклый торган документ күчермәсе (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);

психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсе күчермәсе (бары тик яраклаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Оешмага гариза биргәндә);

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (әлеге Регламентка 7 нче кушымта), тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык

(әлеге Административ регламентка 8 нче кушымта) (дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче булып торган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булса һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый шәхси мәгълүматларны эшкәртү әлеге зат ризалыгы белән гамәлгә ашырыла алса тапшырыла).

Әгәр мөрәҗәгать итүче төп гомуми белем бирү программалары буенча укуга чираттан тыш, беренче чиратта кабул итү яки төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укуга өстенлекле кабул итү хокукына ия булса, ул балигъ булмаган гражданнарны хәрби яки башка дәүләт хезмәтенә, шул исәптән Россия казаклыгының дәүләт хезмәтенә оешмага әзерләү максатыннан өстәмә гомуми үсеш программалары белән интеграцияләнгән булса, ул аның әлеге хокукы барлыгын раслаучы документларны үзе бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче кирәкле документларны тапшырмаган очракта, Оешма хезмәткәре аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә соратып ала.

2.6.1.2. Башка белем бирү оешмасыннан (алга таба – башлангыч оешма) күчерелгән очракта Оешмага кабул итү турында гаризаны кабул кабул итү өчен баланың ата-анасы (законлы вәкиле (вәкилләре)) яки укырга керүче кабул итү турында гариза белән бергә түбәндәге документларны тапшыра:

укучының шәхси эше;

агымдагы уку елында укучының уңышлары турында белешмә (өйрәнелгән уку предметлары, курслар, дисциплиналар (модульләр) исемлеге һәм күләме, уңышларны агымдагы контроль нәтиҗәләре буенча билгеләр һәм арадаш аттестация), башлангыч оешманың мөһере һәм аның җитәкчесе (директоры яки вәкаләтле вәкиле) имзасы белән расланган булырга тиеш.

2.6.1.3. Оешмага килгәч һәм Оешманың вәкаләтле вазыйфаи затлары белән турыдан-туры хезмәттәшлек иткәндә, мөрәҗәгать итүче әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның оригиналын күрсәтә.

Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны рус телендә яисә билгеләнгән тәртиптә рус теленә тәрҗемәсен таныклап тапшыралар.

Гаризаның кәгазь формасы мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры Оешмада алынырга мөмкин.

2.6.2. Гариза бланкының электрон формасы Оешманың рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.3. Кабул итү турында гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

Оешмага шәхсән барган очракта кәгазь чыганакларда;

гомуми файдаланудагы почта элемтәсе операторлары аша, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы хат белән;

63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә ярашлы рәвештә имзаланган (расланган) электрон формада Бердәм портал, Төбәк порталы аша.

2.6.4. Кабул итү турында гаризаны Бердәм портал яки Төбәк порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче кабул итү турында гариза биргән көнне Бердәм порталдагы яки Төбәк порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча

кабул итү турында гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда кабул итү турында гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

Гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Төбәк порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм системада теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Гариза Бердәм портал, Төбәк порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган электрон формадагы документларны тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш) Бердәм портал, Төбәк порталы ярдәмендә җибәрелгәндә, мөрәҗәгать итүче электрон документларның үрнәкләрен мондый документларны электрон рәвештә 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалап, шул исәптән мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар, нотариуслар тарафыннан имзалатып тапшыра.

2.6.2 пунктчасында күрсәтелгән документ гариза бирүченең гади электрон имзасы белән раслана.

Имза төренә карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә файдалану рөхсәт ителгән электрон имза төрләре турында» 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карары нигезендә билгеләнә.

2.6.5. Чит телдә төзелгән документлар рус теленә тәрҗемә ителергә тиеш. Тәрҗемәнең дөреслеге, тәрҗемәченең имзасының чынлыгы Россия Федерациясенең нотариат турында законнары белән билгеләнгән тәртиптә раслана.

2.6.6. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында вәкаләтле органнардан алынырга тиешле документлар:

баланың яки укырга керүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен раслаучы документ турында мәгълүмат. Бердәм портал, Төбәк порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, шәхесне таныклый торган документтагы белешмәләр ИАБС системасында исәпкә алу язуын раслаган вакытта тикшерелә;

баланың Россия Федерациясе территориясендә тууы турында белешмәләр – Федераль салым хезмәте (алга таба – Федераль салым хезмәте), «Гражданлык хәле актларын теркәү буенча бердәм дәүләт реестры» (алга таба – ГХАТ БДР);

өйләнешү (аерылышу) турында мәгълүмат – ФСХ, ГХАТ БДР;

аталыкны билгеләү турында белешмәләр – ГХАТ БДР;

исем үзгәртү турында мәгълүмат – ГХАТ БДР;

опека яки попечительлек билгеләнүен раслаучы документлар турында мәгълүмат – «Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы;

Россия Федерациясе территориясендә бер ата-анадан туган һәм атасы яисә

анасы бер булмаган ир һәм (яки) кыз туганы тууы турында белешмәләр (бер ата-анадан туган һәм атасы яисә анасы бер булмаган ир һәм (яки) кыз туганы укый торган Оешмада гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укытуга өстенлекле рәвештә кабул итү хокукын кулланганда);

баланы яшәү урыны буенча яки беркетелгән территориядә торган урыны буенча теркәү турында мәгълүмат яки баланың кайда булуы, кайда яшәве турында мәгълүматлар булган документлар (беркетелгән территориядә яшәүче баланы яки укырга керүчене кабул иткән очракта);

балигъ булмаган гражданнарны хәрби яки башка дәүләт хезмәтенә, шул исәптән Россия казакчылыгының дәүләт хезмәтенә әзерләү максатыннан өстәмә гомуми үсеш программалары белән интеграцияләнгән төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча чираттан тыш, беренче чиратта укырга кабул итү хокукын раслаучы мәгълүматлар (мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге документлар мөстәкыйль рәвештә тапшырылмаган очракта) – вәкаләтле органнарга;

психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсе турында мәгълүмат (гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән документлар үзлегеннән тапшырылмаган очракта) – кайсы орган вәкаләтле булуына карап, шул органга;

Белем турында документлар һәм (яисә) квалификация турында документлар турында белешмәләрнең федераль реестрында билгеләнгән тәртиптә (урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул иткәндә) бирелгән төп гомуми белем турында документ турында белешмәләр – Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәткә;

баланы яки укырга керүчене яшәү урыны буенча яки беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәү турында белешмә яки яшәү урыны буенча теркәүне рәсмиләштерү өчен документлар кабул итү турында белешмә (беркетелгән территориядә яшәүче баланы яки укырга керүчене укырга кабул итү очрагында) – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары («Россия ЭЭМ сервис концентраторы» электрон сервисы).

Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

### 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

башка дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү;

гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тәкъдим иткәндә;

гамәлдәге законнарны бозып электрон имза кулланылганда;

документларда Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә

расланмаган текстны чистарту һәм төзәтү урыннары бар, язма гариза тексты һәм (яки) аңа кушылган документлар (документлар күчермәләре) укылмый, гариза тулысынча тутырылмаган;

документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булган очракта;

Бердәм порталда, Төбәк порталында гариза формасындагы мәҗбүри юлларны төгәл итеп тутырмау (тутырмыйча калдыру, төгәл, тулы булмаган итеп яисә әлеге Административ регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килми торган, дөрес булмаган итеп тутыру);

мөрәҗәгать итүченең шәхесне раслаучы документны тапшырмавы, яки шәхесне раслаучы, гамәлдә булу вакыты чыккан документны яки шәхесне раслаучы, гамәлдә булмаган документны тапшыруы;

элек җибәрелгән гариза буенча дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты әле узмаган, элегрәк теркәлгән гаризага охшаш гариза алынган очракта.

әлеге Административ регламентның 2.4.2 пунктында билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтү чорыннан аерылып торган чорда гариза бирү, аларда күрсәтелгән балалар категорияләрен исәпкә алып;

Административ регламентның 2.6.1.1, 2.6.1.2 пунктларында күрсәтелгән документларның формасы яисә эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килмәве;

ата-ана (законлы вәкил) аның мәнфәгатьләрендә эш итүче баланың яше гамәлдәге закон таләпләренә туры килмәве (бала алты яшь һәм алты айга җитмәгән яки башлангыч гомуми белем алу башланган вакытта инде сигез яшькә җиткән), – баланы Оешмага кабул итүгә рөхсәт булмаганда;

мөрәҗәгать итүченең Оешмада каралмаган белем бирү программасына кабул итү турында гариза белән бары тик адаптацияләнгән программаны гамәлгә ашыручы Оешмага мөрәҗәгать итүе.

2.7.2. Кабул итү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны караудан баш тарту турында белдерү, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Административ регламентның 2 нче кушымтасында билгеләнгән формага ярашлы рәвештә рәсмиләштерелә, Оешманың вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә гариза биргәндә күрсәтелгән ысул белән бирелә (җибәрелә).

2.7.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Төбәк порталында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

2.8.2.1. мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү хокукына ия булган затлар категориясенә туры килмәве;

2.8.2.2. тапшырылган гаризада һәм документлардагы белешмәләрнең дөрес булмавы;

2.8.2.3. Бердәм портал, Төбәк порталы аша тапшырылган гаризада һәм ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынган мәгълүматларда каршылыклар булуы.

2.8.3. Мөрәҗәгать итүче шәхси язма гаризасы нигезендә хезмәт күрсәтүдән баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаны кире алу дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кабат мөрәҗәгать итүгә комачауламый.

2.8.4. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Төбәк порталында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны мөрәҗәгать итүче (вәкил) тарафыннан тапшырганда һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта максималь көтү вакыты 15 минуттан артып китмәскә тиеш.

## 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны теркәү вакыты

2.11.1. Оешмага шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза тапшырылган көнне мөрәҗәгать итүчегә гаризаның кабул ителүен раслый торган теркәү номеры белән язу бирелә һәм теркәлгән документлар исемлеге күрсәтелә.

2.11.2. Гариза кабул ителгән көнне теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.11.3. Барлык гаризалар, тапшыру ысулына карамастан, Оешмага кабул итү турында гаризаларны теркәү журналында теркәлә.

## 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз үтеп керә алу максатларында, түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларга, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, тоткарлыксыз дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү өчен кирәкле җайланмаларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү;

9) дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңәргә ярдәм итү.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга һәм дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кулланыла торган чараларга керү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән яңа файдалануга тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга карата гына кулланыла.

### 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документлар кабул ителә, бирелә торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Министрлыкның, Оешманың рәсми сайтында, Бердәм порталда, Төбәк порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтләреннән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

3) Оешма хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Административ регламентны бозуга нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле барлык документлар белән гариза биргән вакытта мөрәҗәгать итүче бер тапкыр Оешма хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлек итә;

Оешмада дәүләт хезмәте күрсәтүнең электрон документ формасындагы нәтиҗәсен кәгазьдә алу зарурлыгы булган очракта, – бер тапкыр.

Мөрәҗәгать итүче кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан яки Төбәк порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Төбәк порталында шәхси кабинеттан алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаның формасы һәм башка документлар белән Бердәм порталда, Төбәк порталында Оешманың сайтында танышу мөмкинлегенә ия һәм, кирәк булган очракта, аларны электрон формада саклый ала.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрдән файдалану мөмкинлеге, алдан авторизация узмыйча гына, Бердәм порталда, Төбәк порталында «Шәхси кабинет» аша гамәлгә ашырыла. Авторизация узганнан соң, мөрәҗәгать итүче бердәм порталда, Төбәк порталында «Шәхси кабинеты» аша түбәндәге мөмкинлекләргә ия була: Бердәм портал, Төбәк порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документны бирү; кирәк булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен (график файлларны) теркәү; дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында белешмәләр алу; дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алу.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, мөрәҗәгать итүчедә гади электрон имза ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имза ачкычын (алга таба – гади электрон имза) алу өчен мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү процедурасын узарга кирәк. ИАБС системасында алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет»

челтәрендәге сайтта урнаштырылган («Интернет» челтәрендәге сайтның домен исеме – esia.gosuslugi.ru/).

Бердәм системада (физик зат буларак) теркәлү процедурасын узганнан соң мөрәҗәгать итүче – физик зат гади электрон имзаны кулланып Бердәм порталда, Төбәк порталында авторизация узарга тиеш. Бердәм порталда, Төбәк порталында «Шәхси кабинет»та авторизацияләнгәннән соң мөрәҗәгать итүче элек бирелгән гаризаларын һәм хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү нәтиҗәләрен карау мөмкинлеген ала.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган башка хезмәтләр каралмаган.

2.14.2. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы гариза составында дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.14.3. Электрон формада хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре.

2.14.3.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Төбәк порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Төбәк порталыннан файдаланып тапшырырга;

3) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Оешманың, шулай ук аның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Бердәм портал, Төбәк порталы, карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә,

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә башкарылган.

2.14.3.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Төбәк порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.3.3. Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;

2) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

3) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

4) ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда, Төбәк порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр гаризаның электрон форма кырларын тутыру;

5) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

6) кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә өч ай дәвамында.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системалары исемлеге:

1) Оешманың рәсми сайты http://edu.tatar.ru;

2) Бердәм портал;

3) Төбәк порталы.

.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары

### 3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедуралардан тора:

1) консультация бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара электрон багланышлар системасы (алга таба – ВЭБС) аша дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү;

4) документлар комплектын һәм мәгълүматларны карау (карар кабул итү өчен документларның һәм мәгълүматларның билгеләнгән критерийларга туры килүен тикшерү);

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә (алга таба – мөрәҗәгать итүчене консультацияләү)

3.2.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе консультацияне башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче Оешмага мөрәҗәгать иткән очракта – Оешма хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә – Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәре.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче Оешмага шәхсән, телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Бердәм порталдан, Төбәк порталыннан, Оешма сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны Оешма сайтыннан, Бердәм порталдан яки Төбәк порталыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Оешма хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Әлеге пунктта каралган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Бердәм порталдан яки Төбәк порталыннан, Министрлык сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Әлеге пунктта каралган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында административ процедураны үти башлау өчен нигез булып Оешмага кабул итү турында гариза кабул итү тора.

3.3.2. Кабул итү турында гаризаны кабул итү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Оешма боерыгы белән билгеләнгән Оешма хезмәткәре тора.

3.3.3. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, почта аша яки электрон рәвештә Бердәм порталны яки Төбәк порталын кулланып, әлеге Административ регламент таләпләренә туры китереп, кабул итү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бирә.

3.3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән Оешмага мөрәҗәгать итә һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1, 2.6.1.1, 2.6.1.2 пунктлары нигезендә документлар тапшыра. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) Оешмага почта аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1, 2.6.1.1, 2.6.1.2 пунктларына ярашлы рәвештә документлар җибәрә.

3.3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Төбәк порталы аша электрон формада кабул итү.

3.3.3.2.1. Бердәм портал, Төбәк порталы аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда яки Төбәк порталында авторизация уза;

Бердәм порталда яки Төбәк порталында электрон гариза формасын ача;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза булуын раслый (электрон гариза формасында тиешле билге билгели);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Кабул итү турында формалаштырылган гаризаны формат-мантыйкый тикшерү Бердәм порталда әлеге Административ регламентта билгеләнгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан кабул итү турында гаризаның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм порталда кабул итү турында гаризаның электрон формасындагы кырларны төгәл тутырмау очрагы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның рәвеше һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры кабул итү турындагы гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткереп, хәбәр ителә.

3.3.4. Кабул итү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза кабул ителгән көнне вазыйфаи зат:

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә, шул исәптән документларның электрон рәвешләренә документларның туры килүен тикшерә;

әлеге Административ регламентның 2.7.1 пунктында булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаса, кабул итү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны терки;

әлеге Административ регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булган очракта, әлеге Административ регламентка 2 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә, сәбәпләрен күрсәтеп, кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү проектын әзерләүне тәэмин итә;

Оешмага шәхсән мөрәҗәгать иткәндә кабул ителгән һәм Оешмага почта аша килгән дәүләт хезмәте күрсәтү һәм кабул итү турында гариза буенча, Бердәм порталга яки Төбәк порталына мәгълүмат кертә һәм электрон эш ача.

3.3.5. Кабул итү турында гаризаны почта элемтәсе аша тапшырганда яки шәхсән биргәндә, мөрәҗәгать итүчегә Оешманың кабул итү турында гаризаны һәм документларны кабул итү өчен җаваплы булган вазыйфаи затының имзасы белән имзаланган, кабул итү турында гаризаның аерым теркәү номерын һәм кабул итүгә документларны кабул иткәндә тапшырылган документлар исемлеген үз эченә алган, әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасында билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелгән документ бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып теркәлгән кабул итү турында гариза һәм аңа кушылган документлар комплекты яки кабул итү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны карауга алудан баш тарту турында белдерү тора.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза килгән көнне башкарыла.

### 3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга ВЭБС аша җибәрү.

3.4.1. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.2. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы ведомствоара мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.3. Ведомствоара мөрәҗәгатьне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат Оешма боерыгы белән билгеләнә. Ведомствоара мөрәҗәгатьне җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

3.4.3.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм портал һәм (яки) Төбәк порталы аша җибәрелгән, гаризага кертелгән бала турында белешмәләр (баланың фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), туган көне, туу турында таныклык реквизитлары буенча идентификацияләү) ГХАТ БДР системасында автомат режимда раслана.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында (кирәк булганда) алына:

баланың яки укырга керүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен раслаучы документ турында мәгълүмат. Бердәм портал, Төбәк порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне раслаучы документ белешмәләре Российскойиа Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнарына (электрон сервис Россия Эчке эшләр министрлыгының сервис концентраторы)исәп язмасын раслаганда тикшерелә;

баланың Россия Федерациясе территориясендә тууы турында мәгълүмат – ФСХ, ГХАТ БДР;

өйләнешү (аерылышу) турында мәгълүмат – ФСХ, ГХАТ БДР;

аталыкны билгеләү турында белешмәләр – ГХАТ БДР;

исем үзгәртү турында мәгълүмат – ГХАТ БДР;

опека яки попечительлек билгеләнүен раслаучы документлар турында мәгълүмат – «Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы;

Россия Федерациясе территориясендә бер ата-анадан туган һәм атасы яисә анасы бер булмаган ир һәм (яки) кыз туганы тууы турында белешмәләр (бер ата-анадан туган һәм атасы яисә анасы бер булмаган ир һәм (яки) кыз туганы укый торган Оешмада гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укытуга өстенлекле рәвештә кабул итү хокукын кулланганда) – ФСХ, ГХАТ БДР;

баланы яшәү урыны буенча яки беркетелгән территориядә торган урыны буенча теркәү турында мәгълүмат яки баланың кайда булуы, кайда яшәве турында мәгълүматлар булган документлар (беркетелгән территориядә яшәүче баланы яки укырга керүчене кабул иткән очракта) – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары;

балигъ булмаган гражданнарны хәрби яки башка дәүләт хезмәтенә, шул исәптән Россия казакчылыгының дәүләт хезмәтенә әзерләү максатыннан өстәмә гомуми үсеш программалары белән интеграцияләнгән төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча чираттан тыш, беренче чиратта укырга кабул итү хокукын раслаучы мәгълүматлар (мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге документлар мөстәкыйль рәвештә тапшырылмаган очракта) – вәкаләтле органнарга;

психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсе турында мәгълүмат (гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән документлар үзлегеннән тапшырылмаган очракта) – кайсы орган вәкаләтле булуына карап, шул органга;

Белем турында документлар һәм (яисә) квалификация турында документлар турында белешмәләрнең федераль реестрында билгеләнгән тәртиптә (урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул иткәндә) бирелгән төп гомуми белем турында документ турында белешмәләр – Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәткә;

баланы яки укырга керүчене яшәү урыны буенча яки беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәү турында белешмә яки яшәү урыны буенча теркәүне рәсмиләштерү өчен документлар кабул итү турында белешмә (беркетелгән территориядә яшәүче баланы яки укырга керүчене укырга кабул итү очрагында) – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары

(«Россия ЭЭМ сервис концентраторы» электрон сервисы);

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслаучы белешмәләр – Федераль нотариаль палата, Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы.

3.4.3.2. Мөрәҗәгать итүчедән әлеге Административ регламентның 2.6.6 пункты нигезендә ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүченең әлеге Административ регламентның 2.6.6 пункты нигезендә ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

3.4.4. Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар кабул итү турында гариза теркәлгән көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып: документлар (мәгълүматлар), җибәрелгән ведомствоара гаризалар тора.

Әлеге Административ регламентның 2.6.6 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Администартив регламентның 2.6.6 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара гариза алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратып алына торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаса, баш тарту турында белдерү ала.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан

тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

Процедураның нәтиҗәсе: соралган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган мәгълүматларны) алу.

3.4.5. Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына укырга керү турында гаризалар кабул иткәндә Татарстан Республикасының башка белем бирү оешмасыннан күчерү тәртибендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек гамәлгә ашырылмый.

3.5. Документлар комплектын һәм мәгълүматларны карау
(карар кабул итү өчен документларның һәм мәгълүматларның
билгеләнгән критерийларга туры килүен тикшерү)

3.5.1. Административ процедураны үти башлау өчен нигез булып әлеге Административ регламентның 2.6.6 пунктында каралган документлар һәм белешмәләр бирү турындагы ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап килү тора.

3.5.2. Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Оешма хезмәткәре тора.

3.5.3. Мөрәҗәгатьләргә җаваплар килгән көнне вазыйфаи зат:

1) кергән гаризаларны һәм аларга кушып бирелгән документларны, шул исәптән документларның электрон рәвешләрен, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавапларны өйрәнә, аларны әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавы буенча тикшерә;

әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, әлеге Административ регламентка 4 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә гариза кабул итү турында белдерү проектын әзерли;

әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, әлеге Административ регламентка 5 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә гаризаны кабул итүдән баш тарту турында белдерү проектын әзерләүне тәэмин итә;

2) Оешма директорына гаризаны кабул итү яки кабул итүдән баш тарту турында белдерү проектын имзалау өчен тәкъдим итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара гаризаларга җаваплар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул итү турында гаризаны кабул итү турында белдерү проекты яисә кабул итү турында гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү проекты.

3.5.4. Оешма директоры гаризаны кабул итү яки кабул итүдән баш тарту турында белдерү проектына кул куя.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гаризаны кабул итү турында яки кабул итүдән баш тарту турында белдерү проекты килгән көнне башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Оешма директоры тарафыннан имзаланган, гаризаны кабул итү турында белдерү яисә гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү проекты

3.5.5. Укучыларны бер Оешмадан икенчесенә күчерү яки укучыларны аерым уку фәннәрен тирәнтен өйрәнү белән төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен яки индивидуаль сайлап алу нәтиҗәләре буенча профильле уку өчен Оешмага күчерү турында гаризаны кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, 3.5.3, 3.5.4 пунктларында билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән соң ике эш көне эчендә башкарыла.

3.5.6. Гаризаны һәм тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча башкаручы зат мөрәҗәгать итүчегә шәхси эш ача, анда тапшырылган барлык документлар (документларның күчермәләре) саклана, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә гариза биргәндә күрсәтелгән ысул белән Оешмага кабул итү турында карар кабул итү вакыты турында хәбәр итә.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.6.1. Административ процедураны үти башлау өчен нигез булып административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затның әлеге Административ регламентның 2.3.1 пунктында каралган белдерүләрнең берсен алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) оешма боерыгы белән билгеләнә.

Оешманың вазыйфаи заты Бердәм порталда яки Төбәк порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ имзаланган көнне, Оешма директоры тарафыннан башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бердәм порталда яки Төбәк порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

3.6.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу ысулын сайлаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырыла яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне Оешманың эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләрне бирү (җибәрү):

гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмасына кабул итү турында гариза кабул итү турында белдерү;

гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмасына кабул итү турында гаризаны кабул итүдән баш тарту турында белдерү.

3.7. Техник хаталарны төзәтү

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Оешмага түбәндәгеләрне җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Административ регламентка 6 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә) яисә Бердәм портал, Төбәк порталы аша җибәрелә.

3.7.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән административ процедура гариза килгән көнне башкарыла.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карауга җибәрелгән, кабул ителгән һәм теркәлгән гариза тора.

3.7.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатларында һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып, тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, Оешмага техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедура техник хата ачыкланганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынучы затның хата турында гаризасын теркәгән көннән соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ тора.

## IV. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затларның Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларны саклавын һәм үтәвен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүен агымдагы тикшереп тору Оешма җитәкчесе (директоры) тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен саклауга һәм үтәүгә карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү сроклары һәм тәртибе үтәлешенә.

4.3. Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәл кылмавы) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.6. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Оешма эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне һәм шикаятьләрне судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## V. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә Оешманың дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Оешма җитәкчесенә (директорына) дәгъва белдерү хокукына ия. Оешма җитәкчесе (директоры) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр – Министрлыкка, министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы, дәүләт хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документлар яки мәгълүматлар яисә гамәлләрне башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен аларның тапшырылуы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Оешманың, Оешма вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен

телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Алынган шикаять кергән көненнән соңгы икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

«Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка 1 нче кушымта

**Форма**

_______________________________ директорына
(Оешманың кыскача исеме)
кемнән ___________________________________________
_____________________________________________
_____________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)[1] тулысынча)
Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны һәм (яки) тору урыны адресы:________________________
____________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең телефоны._________________
Мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресы
_______________________________________________

**Гариза**

Сездән минем улымны (кызымны)/мине ___________________________________________ __________ сыйныфка[2] укырга кабул итүегез турында сорыйм.
(баланың яисә 14 яшькә җиткән укырга керүченең фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта) – тулысынча)
______________________________________________________________________________ризалыгы белән
(укырга керүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы - булган очракта) (тулысынча), гариза турыдан-туры 14 яшен тутырган, балигълык яшенә җитмәгән укырга керүче тарафыннан бирелгән очракта рәсмиләштерелә).
Баланың яки укырга керүченең туу датасы______________________________________________.
(туган көне, ае, елы)
Баланың яки укырга керүченең яшәү урыны һәм (яки) тору урыны адресы ________________________
__________________________________________________________________________________.

Баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) фамилияләре, исемнәре, ата исеме (булган очракта):
анасы / уллыкка алучы / опекун _____________________________________________________,
(кирәклесенең астына сызарга)
атасы / уллыкка алучы / опекун _____________________________________________________.
(кирәклесенең астына сызарга)

Чираттан тыш кабул итү хокукым бар_____________________________________________________.
(чираттан тыш кабул итүнең нигезе күрсәтелә (булган очракта))
Беренче чиратта кабул итү хокукым бар _________________________________________________.
(беренче чираттагы кабул итү нигезе күрсәтелә (булган очракта))

Минем өстенлекле рәвештә кабул ителү хокукым бар: баланың бертуган (бертуган булмаган) абыйсы (апасы)
___________________________________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта) күрсәтелә )
_____ сыйныфта укучы булып тора (Оешманың кыскача исеме).

Белем алу теле (Россия Федерациясе халыклары телләренә караган туган телендә яки чит телдә белем алган очракта) __________________________;

---

[1] Мөрәҗәгать итүче – башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул иткәндә баланың ата-анасы (законлы вәкиле) яки укырга керүче. Төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул иткәндә, 14 яшькә зат та гариза бирүче була ала.
[2] Кирәк булганда, монда ук сыйныфның укыту профиле (юнәлеше) күрсәтелә.

Россия Федерациясенең республика дәүләт теле (Оешмада Россия Федерациясенең республика дәүләт телен өйрәнү мөмкинлеге бирелгән очракта) ————————————————————————;

(Оешманың кыскача исеме) тарафыннан бирелә торган мөмкинлекләр чикләрендә Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган тел буларак өйрәнү өчен

______________________________________________ телен сайлыйм.

(рус яки татар теле яисә Оешмада укытыла торган башка тел күрсәтелә)

Баланың / укырга керә торган баланың яраклаштырылган белем бирү программасы буенча укытуга һәм (яки) сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән укучы балага психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе (булган очракта) нигезендә яки индивидуаль тернәкләндерү программасы нигезендә инвалидка (инвалид балага) белем һәм тәрбия бирүне оештыру өчен махсус шартлар тудыруга ихтыяҗы бар – ______________________________.[3]

(әйе / юк)

Баланы / мине яраклаштырылган программалар буенча укыту белән килешәм (яраклаштырылган белем бирү программасы белән укыту зарурлыгы булган очракта).[4]

____________________ ____________________

(дата) (имза)

Укытуны тәэмин итү максатыннан, шәхси мәгълүматларны кәгазьдә дә, электрон рәвештә дә «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә эшкәртүгә риза.

____________________ ____________________

(дата) (имза)

Балага/ укырга керүчегә карата өстәмә белешмәләр:[5]

медицина полисы №_____________________________________ бирелгән _________________

дәүләт пенсия иминиятенең иминият таныклыгы №__________________________.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) турында өстәмә мәгълүмат:

ана / уллыкка алучы / опекун_______________________________________________________

__________________________________________________________________________________________,

(эш урыны, вазыйфасы, эш тел., кесә тел.)

ата / уллыкка алучы / опекун ____________________________________________________

__________________________________________________________________________________________.

(эш урыны, вазыйфасы, эш тел., кесә тел.)

____________________ ____________________

(дата) (имза)

*Оешма исемен күрсәтергә* уставы белән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия белән, дәүләт аккредитациясе турындагы таныклык, оешмада гамәлгә ашырыла торган гомуми белем бирү программалары һәм мәгариф эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны, укучыларның хокукларын һәм бурычларын регламентлый торган башка документлар белән танышып чыктым.

____________________ ____________________

(дата) (имза)

14 яшькә җиткән балигъ булмаган укучылар тарафыннан тутырыла

____________________________________________________________________________ризалыгы белән

(укырга керүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы - булган очракта) (тулысынча), гариза турыдан-туры 14 яшен тутырган, балигълык яшенә җитмәгән укырга керүче тарафыннан бирелгән очракта рәсмиләштерелә).

---

[3] Бу абзацта, булган нигезләргә туры китереп, кирәклесе астына сызарга.

[4] Укырга керүче зат унсигез яшькә җиткән очракта.

[5] Биредәге һәм түбәндәрәк урнаштырылган өстәмә белешмәләр тутыру өчен зарури түгел.

«Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка 2 нче кушымта

**Форма**

Кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны карауга алудан баш тарту турында **белдерү**

**«___»_________ 20__ ел.**

Бирелде __________________________________________________________________,
(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
аңа документларны теркәүдән баш тартылды

________________________________________________________________________________
Оешманың кыскача исемен күрсәтергә

сәбәбе:_________________________________________________________________________
(Административ регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр исемлеге)

________________________________________________________________________________

Теркәү №_______ «___»________ 202__ ел.

Документларны кабул итү өчен җаваплы затның имзасы _______________________

«Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка 3 нче кушымта

**Форма**

**Шәхсән килгәндә тапшырылган документларны кабул итү турында язу**

